**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

---

2024елның «01» феврале 5-РС номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына, аларга карарта генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән торак пунктлар чикләрендә урнашкан, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, торак пунктлар чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9,20,21 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2023 елның 25 декабрендәге 10-53/16256 номерлы уңай бәяләмә нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Лаеш муниципаль районы Советының 2011 елның 19 декабрендәге 117-ТР номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге торак пункт чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә, әлеге карарга кушымта нигезендә, кертергә:

- Макаровка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Ташкирмән авылын;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында https://fgistp.economy.gov.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

**Башлык – муниципаль район Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**